КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 20 декабрь г.Казань № 1370

2023 елга Татарстан Республикасында транспорт чараларына техник тикшерү үткәргән өчен түләүнең иң чик күләмнәрен билгеләү турында

«Транспорт чараларын техник тикшерү турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2011 елның 1 июлендәге 170-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Транспорт чараларына техник тикшерү үткәрү кагыйдәләрен раслау турында, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 15 сентябрендәге 1434 номерлы карары, Федераль антимонополия хезмәтенең 2022 елның 30 июнендәге 489/22 номерлы боерыгы белән расланган Техник тикшерү үткәргән өчен түләүнең иң чик күләмен исәпләү методикасы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2023 елның 1 гыйнварыннан 2023 елның 31 декабренә кадәр Татарстан Республикасында транспорт чараларына техник тикшерү үткәргән өчен түләүнең иң чик күләмен кушымта нигезендә билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«Татарстан Республикасында транспорт чараларына техник тикшерү үткәргән өчен түләүнең иң чик күләмнәрен билгеләү турында» 2011 ел, 27 декабрь, 179 нчы;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында транспорт чараларына техник тикшерү үткәргән өчен түләүнең иң чик күләмнәрен һәм техник тикшерү талоны дубликатын рәсмиләштерү чыгымнарының иң чик күләмен билгеләү турында» 2011 ел, 27 декабрь, 179 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 ел, 04 июль, 553 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында транспорт чараларына техник тикшерү үткәргән өчен түләүнең иң чик

күләмнәрен билгеләү турында» 2011 ел, 27 декабрь, 1079 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 ел, 21 декабрь, 1257 нче.

3. Бу карар 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитетына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 20 декабрь, 1370 нче
карарына кушымта

Татарстан Республикасында транспорт чараларына техник тикшерү үткәргән өчен түләүнең иң чик күләмнәре

| Т/с | Транспорт чарасы категориясе | Сумма, сум |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1. | M1 | 913,0 |
| 2. | M2 | 1 563,0 |
| 3. | M3 | 1 888,0 |
| 4. | N1 | 999,0 |
| 5. | N2 | 1 821,0 |
| 6. | N3 | 1 966,0 |
| 7. | O1, O2 | 753,0 |
| 8. | O3, O4 | 1 272,0 |
| 9. | L | 321,0 |
| 10. | Оператив хезмәтләрнең махсус транспорт чаралары (M1 базасында) | 974,0 |
| 11. | Оператив хезмәтләрнең махсус транспорт чаралары (M2 базасында) | 1 563,0 |
| 12. | Оператив хезмәтләрнең махсус транспорт чаралары (M3 базасында) | 1 783,0 |
| 13. | Оператив хезмәтләрнең махсус транспорт чаралары (N1 базасында), транспорт чаралары - цистерналар (N1 базасында), транспорт чаралары - сыекландырылган углеводород газларын (N1 базасында) ташу һәм ягулык салу өчен цистерналар (N1 базасында), транспорт чаралары - фургоннар (N1 базасында), транспорт чаралары - кешеләрне йөртү өчен урыннар булган фургоннар (N1 базасында), автоэвакуаторлар (N1 базасында) | 1 061,0 |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| 14. | Оператив хезмәтләрнең махсус транспорт чаралары (N2 базасында), автомобиль эвакуаторлары (N2 базасында), йөк күтәрү җайланмалары булган транспорт чаралары (N2 базасында), транспорт чаралары - цистерналар (N2 базасында), транспорт чаралары - сыекландырылган углеводород газларын күчереп йөртү һәм ягулык салу цистерналары (N2 базасында), фургоннар (N2 базасында), азык-төлек продуктларын ташу өчен транспорт чаралары (N2 базасында) | 1 907,0 |
| 15. | Оператив хезмәтләрнең махсус транспорт чаралары (N3 базасында), автоэвакуаторлар (N3 базасында), йөк күтәрү җайланмалары булган транспорт чаралары (N3 базасында), транспорт чаралары - цистерналар (N3 базасында), транспорт чаралары - сыекландырылган углеводород газларын күчереп йөртү һәм ягулык салу өчен цистерналар (N3 базасында), транспорт чаралары - фургоннар (N3 базасында), азык-төлек продуктларын ташу өчен транспорт чаралары (N3 базасында) | 2 053,0 |
| 16. | Оператив хезмәтләрнең махсус транспорт чаралары (O1, O2 базасында), транспорт чаралары - цистерналар (O1, O2 базасында), транспорт чаралары - сыекландырылган углеводород газларын (O1, O2 базасында), транспорт чаралары - фургоннар (O1, O2 базасында), азык-төлек продуктларын ташу өчен транспорт чаралары (O1, O2) ташу өчен цистерналар (O1, O2 базасында) | 783,0 |
| 17. | Оператив хезмәтләрнең махсус транспорт чаралары (O3, O4 базасында), автоэвакуаторлар (O3, O4 базасында), йөк күтәртү җайланмалары булган транспорт чаралары (O3, O4 базасында), цистерналар, сыекландырылган углеводород газларын (O3, O4 базасында), фургоннар (O3, O4 базасында), азык-төлек продуктларын ташу өчен транспорт чаралары (O3, O4 базасында) | 1 330,0 |
| 18. | Оператив хезмәтләрнең махсус транспорт чаралары (L базасында) | 353,0 |
| 19. | Махсуслаштырылган транспорт чаралары (N1 базасында), нефть продуктларын ташу һәм ягулык салу цистерналары (N1 базасында) | 1 155,0 |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| 20. | Махсуслаштырылган транспорт чаралары (N2 базасында), нефть продуктларын ташу һәм ягулык салу цистерналары (N2 базасында), транспорт чаралары - кешеләрне йөртү өчен урыннары булган фургоннар (N2 базасында) | 2 081,0 |
| 21. | Махсуслаштырылган транспорт чаралары (N3 базасында), кешеләрне йөртү өчен урыннары булган фургоннар (N3 базасында), нефть продуктларын ташу һәм ягулык салу өчен цистерналар (N3 базасында) | 2 256,0 |
| 22. | Махсуслаштырылган транспорт чаралары (O1, O2 базасында) | 873,0 |
| 23. | Махсуслаштырылган транспорт чаралары (O3, O4) | 1 475,0 |
| 24. | Коммуналь хуҗалык һәм юлларны тоту өчен махсус транспорт чаралары (N1 базасында) | 1 093,0 |
| 25. | Коммуналь хуҗалык һәм юлларны карап тоту өчен махсус транспорт чаралары (N2 базасында), йөк ташу өчен прицеп-роспуска кулланып (N2 базасында) | 1 994,0 |
| 26. | Коммуналь хуҗалык һәм юлларны карап тоту өчен махсус транспорт чаралары (N3 базасында), йөк ташу өчен прицеп-роспуска кулланып (N3 базасында) | 2 169,0 |
| 5 % | Коммуналь хуҗалык һәм юлларны карап тоту өчен махсус транспорт чаралары (O1, O2 базасында), транспорт чаралары - нефть продуктларын ташу һәм ягулык салу өчен цистерналар (O1, O2 базасында) | 843,0 |
| 28. | Коммуналь хуҗалык һәм юлларны карап тоту өчен махсус транспорт чаралары (O3, O4 базасында), транспорт чаралары - нефть продуктларын ташу һәм ягулык салу өчен цистерналар (O3, O4 базасында) | 1 388,0 |
| 29. | Куркыныч йөкләрне ташу өчен транспорт чаралары (N1 базасында) | 1 311,0 |
| 30. | Куркыныч йөкләрне ташу өчен транспорт чаралары (N2 базасында) | 2 370,0 |
| 31. | Куркыныч йөкләрне ташу өчен транспорт чаралары (N3 базасында) | 2 545,0 |
| 32. | Куркыныч йөкләрне ташу өчен транспорт чаралары (O1, O2 базасында) | 904,0 |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| 33. | Куркыныч йөкләрне ташу өчен транспорт чаралары (О3, О4 базасында) | 1 533,0 |
| 34. | Шәһәр җир өсте электр транспорты | 1 311,0 |